КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 2 ноябрь г.Казань № 838

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасында мемориаль такталар кую тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында” 2002 ел, 1 апрель, 163 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасында мемориаль такталар кую тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында” 2002 ел, 1 апрель, 163 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында мемориаль такталар кую тәртибе турында нигезләмә нигезендә эш итәргә һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә мемориаль такталар кую тәртибе турында нигезләмәне, мемориаль такталар буенча комиссия турында нигезләмәне һәм аның составын расларга тәкъдим итәргә.»;

5 пунктта «, Татарстан Республикасы шәһәрләре һәм районнары администрацияләре» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында мемориаль такталар (истәлекле билгеләр) кую тәртибе турында нигезләмәдә:

исемендә «(истәлекле билгеләр)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.1 пунктның икенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

1.7 пунктта «, шәһәр һәм район администрацияләре» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.1 пунктта:

икенче абзацта «10 ел» сүзләрен «1 ел» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «20 ел» сүзләрен «5 ел» сүзләренә алмаштырырга;

4.3 пунктта «атасының исеме» сүзләреннән соң «(булганда)» сүзен өстәргә;

5.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, милек формасын бәйсез оешмалар, шулай ук кимендә 10 кешедән торган гражданнар төркемнәре мемориаль тактаны кую өчен инициатор (алга таба – инициатор) була ала.»;

5.2 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.2. Мемориаль тактаны кую өчен инициатор Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына түбәндәге документларны тәкъдим итә:»;

унберенче абзацта «учреждениеләр, оешмалар, граждан» сүзләрен «инициатор» сүзенә алмаштырырга, «сораучы оешма» һәм «(истәлек билгесе)» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«шәһәр, авыл җирлегендә мемориаль такта куелган очракта җирлекнең вәкиллекле органы һәм территориясендә әлеге җирлек урнашкан муниципаль район башлыгы белән килештерү;

шәһәр округының вәкиллекле органы һәм шәһәр округы башлыгы белән килештерү.»;

5.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.3. Әлеге Нигезләмәнең 5.2 пункты нигезендә инициатор тапшырган документлар Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының мемориаль такталар буенча комиссиясе (алга таба – Комиссия) тарафыннан карап тикшерелә.»;

5.4 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.4. Комиссия составына Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты (килешү буенча), Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты, территориясендә мемориаль такта урнаштыру планлаштырылган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органы (килешү буенча), «Татарстан Республикасының Милли музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе, «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге тарих институты» дәүләт бюджет учреждениесе, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Татар энциклопедия һәм төбәкләрне өйрәнү институты, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институты, иҗади һәм иҗтимагый оешмалар вәкилләре керә. Кирәк булган очракта Комиссия үз эшенә төрле оешмалар һәм ведомстволар белгечләрен җәлеп итә ала.»;

5.5 пунктка «документлар кергән көннән соң бер ай вакыт эчендә» сүзләрен өстәргә;

5.6 пунктта:

беренче абзацка «Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы» сүзләреннән соң «мондый карарны кабул иткән көннән соң бер ай вакыт эчендә» сүзләрен өстәргә;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«территориясендә мемориаль такта кую тәкъдим ителә торган Татарстан Республикасы муниципаль районы башлыгы белән килештерү.»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Комиссия тискәре карар кабул иткән очракта мондый карар кабул ителгән көннән соң 15 көн эчендә бу хакта инициаторга хәбәр ителә.»;

VI бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«VI. Мемориаль такталарны кую, карап тоту һәм исәпкә алу тәртибе

6.1. Мемориаль такталарның зурлыгы һәм кую урыны Комиссия утырышында карап тикшерелә һәм килештерелә. Мемориаль такта кую биналар, корылмалар һәм инженер челтәрләр конструкцияләренә зыян салмаска тиеш.

6.2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының мемориаль такта кую турында карарын кабул иткәннән соң инициатор аны әзерләү һәм кую чараларын гамәлгә ашыра.

6.3. Кирәк булган очракта (бина, корылманың алгы ягы канәгатьләнмәслек хәлдә булганда) инициатор мемориаль тактаны ачу тантанасын үткәргәнче бина, корылманың алгы ягына ремонт башкара.

6.4. Торак һәм торак булмаган йортлар (күпфатирлы торак йортлардан тыш) биналарына куелган мемориаль такталарны инициатор бинаның милекчесе (аннан файдаланучы) балансына тапшыра яки аларны куйган оешма балансына кабул ителә.

Күпфатирлы торак йортлар биналарына куелган мемориаль такталарны инициаторлар территорияләрендә әлеге күпфатирлы торак йортлар урнашкан муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты балансына тапшыра яки аларны куйган оешма балансына кабул ителә.

6.5. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары һәм балансларында мемориаль такталар булган оешмалар аларны саклау һәм гамәлдә карап тоту буенча чаралар күрә.

6.6. Мемориаль такталарның исәбен алу һәм аларның торышын контрольдә тоту территорияләрендә мөһим тарихи вакыйгалар булган, күренекле шәхесләр яшәгән яки эшләгән биналар, корылмалар һәмм истәлекле урыннар урнашкан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

6.7. Мемориаль тактаны алу турында карар (аны реставрацияләү таләп ителгән яки такта куелган бинада ремонт-реставрация эшләре үткәрелә торган очраклардан тыш) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кабул ителә.»;

7.2  пунктның икенче абзацын төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры A.В.Песошин